**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге**
**Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324**
**Азнакаевский район**
**Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**Үзәк урам, 39, Азнакай районы**
**Чалпы авылы, 423324**
**Тел. (8-5592) 35-5-46,**
**факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» октябрь 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чалпы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Камышлы т. п., Молодежная ур., 35 йорт адресы буенча урнашкан Камышлы мәдәният йорты бинасында 2023 елның 09 ноябрендә 13.00 сәгать 00 минутта 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар,аларның гаилә әгъзаларыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнар тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Молодежная урамы буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Камышлы авылында урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү;

- һәйкәлләрне ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү ( материаллар сатып алу, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);

- Камышлы торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы __________ А.М.Мөхәмәтшин
(имза) (имза расшифровкасы)